**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

20.09.2022 г. Казань **№ 152од**

Социаль ориентлашкан коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе нигезендә, боерам:

1. Социаль ориентлашкан коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымта итеп бирелә торган административ регламентын (алга таба - Регламент) расларга.
2. Министр урынбасарларына, структур бүлекчәләр җитәкчеләренә, дәүләт хезмәте күрсәтүне турыдан-туры тәэмин итүче затларга Регламент нигезләмәләренә тайпылышсыз таянып эш итәргә.
3. Хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының «Татарстан Республикасы рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составындагы рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Норматив хокукый актларны теркәү һәм хокукый тәэмин итү бүлегенә әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашырырга.
5. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының түбәндәге боерыкларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Социаль ориентлашкан коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 26 октябрендәге 137 од номерлы боерык;

«Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 13 сентябрендәге 120 од номерлы боерык;

«Социаль ориентлашкан коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү хакында» 2019 елның 9 декабрендәге 161 од номерлы боерык;

«Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 5 августындагы 75од номерлы боерык;

«Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 2 октябрендәге 103од номерлы боерык;

«Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 20 ноябрендәге 132од номерлы боерык.

6. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы юстиция министрының беренче урынбасары А.Г. Галимовка йөкләргә.

Министр Р.И. Заһидуллин

Татарстан Республикасы
Юстиция министрлыгының
2022 елның 20 сентяберендәге
152од номерлы боерыгы
белән расланган

# СОЦИАЛЬ ОРИЕНТЛАШКАН КОММЕРЦИЯЛЕ БУЛМАГАН ОЕШМАЛАР ТАРАФЫННАН КҮРСӘТЕЛӘ ТОРГАН ИҖТИМАГЫЙ ФАЙДАЛЫ ХЕЗМӘТЛӘРНЕҢ БИЛГЕЛӘНГӘН КРИТЕРИЙЛАРГА ТУРЫ КИЛҮЛӘРЕ ТУРЫНДА БӘЯЛӘМӘЛӘР БИРҮ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕ КҮРСӘТҮНЕҢ АДМИНИСТРАТИВ РЕГЛАМЕНТЫ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килүләре турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы (алга таба - Министрлык) тарафыннан социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килүләре турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтүнең тәртибен һәм стандартын билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр булып «Коммерцияле булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы $2^2$ пунктының 1 пунктчасында каралган социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар (алга таба - социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар, коммерцияле булмаган оешмалар) тора.

1.3. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә профильләштерү (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү варианты нигезендә мөрәҗәгать итүченең Министрлык тарафыннан үткәрелә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) үткәрелми.

## 2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте атамасы

Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүләре турында бәяләмәләр (алга таба - бәяләмә) бирү.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган атамасы

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы (алга таба – Министрлык).

Дәүләт хезмәтен башкаручы - Министрлыкның түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне оештыру һәм планлаштыру бүлеге (алга таба – Бүлек).

Дәүләт хезмәте дәүләт хезмәтен һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба – КФҮ) аша күрсәтелми.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып тора:

1) Социаль ориентлашкан коммерциячел булмаган оешманы «Иҗтимагый файдалы хезмәтләрне башкаручылар - коммерциячел булмаган оешмалар реестры турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карары белән расланган иҗтимагый файдалы хезмәтләрне башкаручы дип тану турында карар кабул итү кагыйдәләренә 2 нче кушымта нигезендә форма буенча бәяләмә (алга таба - Кагыйдәләр);

2) бәяләмә бирүдән баш тарту турында мотивлаштырылган белдерү (әлеге Регламентка 2 нче кушымта).

Йомгаклау һәм бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы мотивацияле хәбәр Министрлык бланкында рәсмиләштерелә.

Реестрдагы язма дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торсый.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе Татарстан Республикасының нинди дә булса дәүләт мәгълүмат системасында теркәлми.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә үзе сайлаган алу ысулы нигезендә бирелә (җибәрелә):

гариза бирүчегә язма формадашәхсән бирелә яки почта аша җибәрелә;

электрон почта адресына яки Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (https://www.gosuslugi.ru) (алга таба -Бердәм портал) (техник мөмкинлекләр булганда) мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына яки Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталында (https://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Республика порталы) мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына электрон документ рәвешендә җибәрелә.

2.3.3. Гариза бирүче электрон документ нөсхәсе рәвешендә дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәләрен кәгазьдә алуга хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен кәгазьдә алу өчен гариза бирүче Министрлыкка мөрәҗәгать итә.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы

2.4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар гариза бирүче тарафыннан почта аша яисә шәхсән тапшырылган очракта, дәүләт хезмәте Министрлык тарафыннан гариза һәм документлар теркәлгәннән соң 30 көн эчендә күрсәтелә.

2.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинеты аша Бердәм порталда яки Республика порталында бирелгән очракта, дәүләт хезмәте Министрлык тарафыннан гаризага эшләр номенклатурасы нигезендә номер һәм Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда) яки Республика порталының шәхси кабинетында чагылдырала торган «Документларны тикшерү» статусы бирелгән көннән 30 көн эчендә күрсәтелә.

Министрлык тарафыннан Кагыйдәләрнең 6 пункты нигезендә запрослар җибәрелгән очракта әлеге срок 30 көннән дә артык булмаган вакытка озайтылырга мөмкин.

Әлеге карарны кабул итү вакытын озайту турында Министрлык мөрәҗәгать итүчегә гариза кергән көннән 30 көн эчендә хәбәр итә.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

Министрлыкның рәсми сайтында һәм Бердәм порталда (техник мөмкинлек булганда) һәм Республика порталында урнаштырыла:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп торуны гамәлгә ашыру өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

дәүләт хезмәте күрсәтүче Министрлыкның, вазыйфаи затның, дәүләт граждан хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге, аларны гариза бирүче үзе тапшыра:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба-гариза):

билгеләнгән форма буенча кәгазьдә документ рәвешендә (әлеге Регламентка 1 нче кушымта);

Бердәм портал яки Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, әлеге Регламентның 2.6.4 пункты таләпләре нигезендә имзаланган электрон формада (тиешле мәгълүматларны гаризаның электрон формасына кертү юлы белән тутырыла);

б) оештыру документларының күчермәләре;

в) мөрәҗәгать итүче вәкиленең шәхесен раслаучы документ (Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта бирелә). Бердәм портал яки Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә шәхесне раслаучы документтан белешмәләр электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада бердәм идентификация һәм аутентификация системасында (алга таба - ЕСИА) хисап язмасын раслаганда тикшерелә.

2.6.2. Гариза бирүче тарафыннан күрсәтелә торган хезмәт күрсәтүнең иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләүнең билгеләнгән критерийларына туры килүен нигезләүче документлар (белешмә, характеристика, эксперт бәяләмәләре, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары каршындагы Иҗтимагый советларның бәяләмәләре һәм башкалар) беркетелергә мөмкин.

Мөрәҗәгать итүче тиешле иҗтимагый файдалы хезмәт буенча социаль хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән очракта, мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын бәяләүнең билгеләнгән критерийларына туры килүен нигезли торган өстәмә документлар тапшыру таләп ителми.

2.6.3. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен алу өчен гариза бланкын Бүлеккә шәхси мөрәҗәгать иткәндә ала ала. Гариза бланкының электрон формасы Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

2.6.4. Гариза һәм аңа беркетелгән документлар гариза бирүче тарафыннан шәхсән яисә почта аша тапшырыла ала.

Гариза һәм документлар шулай ук «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) гариза бирүче имзалаган (раслаган) электрон документ рәвешендә, Бердәм портал аша (техник мөмкинлек булганда) яки Республика порталы аша тапшырыла ала.

Гариза, Бердәм портал яки Республика порталы аша юллаганда, мөрәҗәгать итүченең гади электрон имзасы белән имзалана.

Гади электрон имза алу өчен гариза бирүчегә ЕСИАга теркәлү (аутентификация) процедурасын үтәргә, шулай ук исәпкә алыну язмасын стандарттан түбән булмаган дәрәҗәгә расларга кирәк.

Гаризага беркетелгән электрон документлар (документларның электрон образлары), шул исәптән ышаныч кәгазьләре файл рәвешендә pdf, jpg, jpeg, png, tif, doc, docx, rtf форматларында җибәрелә.

2.6.5. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиешле документлар

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Министрлык тарафыннан оешманың «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 44-ФЗ номерлы федераль закон) нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтүләр нәтиҗәләре буенча намуссыз тәэмин итүчеләр реестрында булмавын раслаучы документлар, гариза бирүче документлар тапшырган айның беренче числосына гариза бирүче турында социаль хезмәт күрсәтүләрне тиешле иҗтимагый файдалы хезмәт буенча тәэмин итүчеләр реестрына язма кертү факты соратып алына.

Мөрәҗәгать итүче бу пунктта күрсәтелгән белешмәләре булган документларны тапшырырга хокуклы, шул исәптән мөмкинлек булганда – электрон формада.

Гариза бирүченең югарыда күрсәтелгән белешмәләр булган документларын тапшырмавы гариза бирүчегә хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез түгел.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итмәү өчен нигезләрнең тулы исемлеге

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итмәү өчен нигезләр:

әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган исемлеген тапшыру;

63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) таләпләре нигезендә гади электрон имза белән имзаланмаган (расланмаган) гариза һәм документлар (документлар күчермәләре) тапшыру (электрон формада гариза биргәндә).

Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм башка документлар дәүләт хезмәте күрсәтүнең сроклары һәм тәртибе турында Бердәм порталда яки

Республика порталында, Министрлыкның рәсми сайтында бастырылган мәгълүматлар нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр законда каралмаган.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:

а) иҗтимагый файдалы хезмәтнең аның эчтәлегенә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве (күләме, вакыты, сыйфаты);

б) иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы затларның (шул исәптән оешма хезмәткәрләренең, граждан-хокукый характердагы килешүләр буенча җәлеп ителгән хезмәткәрләрнең) тиешле квалификациясе (шул исәптән һөнәри белем бирү, тиешле өлкәдә эшләү тәҗрибәсе) булмау, тиешле квалификациясе булган затларның җитәрлек булмавы;

в) бәяләмә бирү алдыннан алдагы ике ел эчендә иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтү белән бәйле оешманың гамәлләренә (гамәл кылмавына) суд тарафыннан, аларның компетенциясе нигезендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек органнары, аларның компетенциясе нигезендә бүтән дәүләт органнары тарафыннан нигезләнгән шикаятьләр булу;

г) оешма турында мәгълүматның ачыклык дәрәҗәсе һәм аны алу мөмкинлеге Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә (алар булганда) туры килмәве;

д) бәяләмә бирү алдыннан алдагы ике ел эчендә намуссыз тәэмин итүчеләр реестрында 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән килешүләрне үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча оешма турында мәгълүмат булу;

е) дөрес булмаган мәгълүматлар булган яки тиешле тәртиптә рәсмиләштерелгән документлар тапшыру.

2.8.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтүнең сроклары һәм тәртибе турында Бердәм порталда яки Республика порталында, Министрлыкның рәсми сайтында бастырылган мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән алына торган түләү күләме һәм аны түләү ысуллары

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында запрос биргәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда максималь көтү вакыты

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында запрос биргәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда максималь көтү вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.11. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризасын теркәү вакыты

2.11.1. Министрлыкка шәхси мөрәҗәгать иткәндә теркәлү гариза һәм документлар кергән көнне башкарыла. Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соңгы эш көнендә теркәлә.

2.11.2. Гаризаны Бердәм портал яки Республика порталы аша җибәргәндә мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Бердәм порталда (техник мөмкинлек булганда) яки Республика порталындагы шәхси кабинетында һәм электрон почта аша гаризаның җибәрелүен, анда теркәү номеры һәм гариза бирү датасы күрсәтелүен раслаучы белдерү ала.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы җиһазландырылган биналарда гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү урыннары документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель һәм мәгълүмати стендлар белән җиһазландырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның мөмкинлекләре чикләнгән булуны исәпкә алып урнаштырыла.

2.12.2. Инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керүне тәэмин итү максатыннан:

1) бүлмәләргә тоткарлыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

2) хезмәт күрсәтү урынына керү өчен, шул исәптән объект хезмәткәрләре ярдәме белән биналар буйлап мөстәкыйль йөрү мөмкинлеге;

3) транспортка утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән коляскалы урындык куллану;

4) күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функцияләре бозылган инвалидларны озату һәм аларга ярдәм күрсәтү;

5) инвалидларның тормыш эшчәнлегенә чикләүләрне исәпкә алып, урынга тоткарлыксыз керү мөмкинлеген тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөрткечеләрне тиешенчә урнаштыру;

6) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Озатучы этне махсус укытуны раслаучы документ формасын һәм тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386 н номерлы карары белән билгеләнгән форма һәм тәртип буенча бирелә торган документы булганда озатучы этне кертү;

7) хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга хезмәтләрне башка затлар белән беррәттән алуга комачаулый торган киртәләрне җиңәргә ярдәм итү.

2.12.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидларга уңайлылыгы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә кулланыла торган чараларга үтемлелекне тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә модернизацияләнгән, реконструкцияләнгән объектларга һәм чараларга кулланыла.

2.13. Дәүләт хезмәтеннән файдалану һәм сыйфат күрсәткечләре

2.13.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелүнең уңайлылык күрсәткечләре булып торалар:

бина һәм бүлмәләрнең җәмәгать транспорты килеп җитә торган урында булулары;

белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган бина һәм бүлмәләрнең җитәрлек санда булуы;

дәүләт хезмәте күрсәтүнең алымнары, тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүмат стендларында, Министрлыкның рәсми сайтында, Бердәм порталда (техник мөмкинлек булганда) һәм Республика порталында тулы мәгълүмат бирелү;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бина һәм бүлмәләрнең инвалидлар өчен уңайлы булулары;

дәүләт хезмәтен күрсәтүче хезмәткәрләрнең инвалидларга биналарның инвалидлар өчен уңайлылыгына бәйле булмаган, аларга хезмәтләрне башкалар белән тигез дәрәҗәдә алырга комачаулый торган башка киртәләрне үтүдә булышлык итү;

гаризаны электрон вариантта бирү мөмкинлеге;

гариза бирүченең гариза һәм документларны электрон рәвештә Республика порталы аша биргәндә хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен Бердәм порталда (техник мөмкинлек булганда) һәм Республика порталында шәхси кабинет аша алу мөмкинлеге бар.

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтелүнең сыйфат күрсәткечләре булып торалар:

1) документларны кабул итү һәм карау вакытлары саклану;

2) дәүләт хезмәте күрсәтелүнең нәтиҗәләрен алу вакытлары саклану;

3) әлеге Регламент Министрлык белгечләре тарафыннан бозылуга нигезләнгән шикаятьләр булмау;

4) гариза бирүченең бүлек белгечләре белән багланышлары саны:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документларны турыдан-туры биргәндә һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен турыдан-туры алганда -икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

Гариза бирүче белән үзара эш вакыты 15 минуттан артмый.

Мөрәҗәгать итүче кучмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары, Бердәм порталдан (техник мөмкинлек булганда) һәм Республика порталыннан файдаланып дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә хокуклы.

2.13.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турындагы мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан Министрлыкта, Бердәм порталдагы (техник мөмкинлек булганда) һәм Республика порталындагы шәхси кабинетта алынырга мөмкин.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән:

КФҮтә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә алучы;

дәүләт хезмәте турында белешмәләрне Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә бирү турында.

2.14.1 Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү кирәк түгел.

2.14.2. Консультация мөрәҗәгать итүчегә шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта, почта аша бирелергә мөмкин.

2.14.3. КФҮтә дәүләт хезмәте күрсәтү гамәлгә ашырылмый.

2.14.4. Дәүләт хезмәте электрон формада күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон образлары 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешенең 72 пункты нигезендә элек расланган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталны (техник мөмкинлек булганда) һәм Республика порталын кулланып бирергә;

в) дәүләт хезмәте күрсәтү турында электрон формада бирелгән гаризаларны үтәүнең барышы турында мәгълүмат алырга;

г) дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләүне гамәлгә ашырырга;

д) дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәләрен электрон документ рәвешендә алырга;

е) Министрлыкның, шулай ук аның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең карарына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) дәүләт хезмәтләрен күрсәткәндә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан кылынган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процессын тәэмин итә торган Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда) һәм (яки) Республика порталы аша шикаять бирергә.

Гаризаны формалаштыру гаризаны нинди дә булса башка формада бирмичә, Бердәм порталда (техник мөмкинлек булганда) яки Республика порталында электрон формада гариза тутыру юлы белән башкарыла.

2.14.5. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы кулланыла.

2.14.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

2.14.7. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы сорау составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

## 3. Административ процедураларны үтәү вакыты, составы, эзлеклелеге

2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү вариантлары, шул исәптән үз эченә дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы һәм төзелгән реестр язмаларындагы хаталарны төзәтү өчен кирәкле дәүләт хезмәтен күрсәтү вариантларын алган исемлеге

Дәүләт хезмәте, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны төзәтү бердәй вариантта башкарыла һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү сроклары, мөрәҗәгать итүчеләр категорияләре, зурлыгы һәм түләү тәртибе, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге белән аерылып торган дәүләт хезмәте күрсәтүнең аерым сценарийларына; дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә барлыкка килгән документлар һәм юридик яктан әһәмиятле гамәлләргә ия түгел.

3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча бирелгән документның дубликатын бирү өчен вариантлар исемлеге, шул исәптән мондый дубликатны бирүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документның дубликатын бирү гамәлгә ашырылмый.

3.3. Мөрәҗәгать итүчене профильләштерү административ процедурасы тасвирламасы

Мөрәҗәгать итүченең профильләштерү процедурасы үтәлми.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләр эзлеклелегенең тасвирламасы

3.4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү һәм ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запросларны формалаштыру һәм җибәрү;

4) дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен әзерләү;

5) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен бирү (җибәрү)

6) техник хаталарны төзәтү.

3.5. Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүне алу тәртибе турында консультация алу өчен Бүлеккә шәхсән, телефон аша һәм (яки) почта (шул исәптән электрон), шулай ук Бердәм портал аша (техник мөмкинлек булганда) һәм Республика порталы аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә консультация бирә, шул исәптән запрос формасы һәм дәүләт хезмәтен алу өчен башка мәсьәләләр буенча да. Кирәк булса Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: консультация, тапшырыла торган документларның составы, формасы, эчтәлеге буенча искәрмәләр, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм итү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә, гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында консультация бирү (мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү) турында язма.

3.6. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.6.1. Гариза бирүче документларын Министрлыкның үтәүне контрольдә тоту бүлегенә гаризаны шәхсән яисә ышанычлы зат аша, почта, электрон почта, Бердәм портал аша (техник мөмкинлек булганда) һәм Республика порталы аша бирә ала.

Гариза почта аша заказлы хат итеп җибәрелергә мөмкин.

Электрон формада җибәрелә торган гариза 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә имзалана (раслана) һәм «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы электрон йөрткечләр һәм (яки) мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрләр ярдәмендә тапшырыла.

Почта аша заказлы хат итеп яки электрон формада бирелгән гариза гомуми тәртиптә карала.

3.6.1.1. Бүлек белгече бирелгән документларның әлеге Регламентның 2.6 пункты таләпләренә туры килү-килмәвен тикшерә.

3.6.1.2. Мөрәҗәгать итүче шәхсән яки ышанычлы зат аша мөрәҗәгать иткәндә документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган нигез булган очракта, Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту өчен нигезләр булу турында хәбәр итә һәм документлар кире кайтара. Таләп буенча баш тарту язма рәвештә рәсмиләштерелә.

Гариза һәм документларны почта (электрон почта) аша җибәргәндә Бүлек белгече аңа, документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, документларны почта аша (электрон почта) кире кайтара.

3.6.1.3. Министрлыкның документларын үтәүне тикшереп тору бүлеге белгече документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булмаган очракта гариза һәм документларны Министрлыкның эш башкаруы буенча инструкция белән билгеләнгән тәртиптә теркәп куя һәм Бүлеккә тикшерүгә җибәрә.

Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү турында гариза Бүлеккә электрон почта аша яки Интернет-кабул итү бүлмәсе аша җибәрелә.

Әлеге Регламентның 3.6.1.1-3.6.1.3 пунктларында билгеләнгән процедуралар Министрлыкка гариза һәм документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: теркәлгән гариза һәм документлар.

3.6.2. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза һәм документларны Бердәм портал аша (техник мөмкинлек булганда) һәм Республика порталы аша кабул итү

3.6.2.1. Гариза бирүче гаризаны электрон формада тапшыру өчен:

авторизация башкара;

электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

документларны электрон формада яки электрон документ образларын электрон гариза формасына беркетә (кирәк булса);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гаризада ризалык турында тиешле билгене куя);

хәбәр ителгәннәрнең дөреслеген раслый (электрон гаризада ризалык турында тиешле билгене куя);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасында тиешле төймәгә баса);

электрон гаризага әлеге Регламентның 2.6.4 пункты таләпләре нигезендә имза салына;

электрон гаризаны җибәрү турында хәбәр ала.

Формалаштырылган гаризаны формат-логик тикшерү, гариза бирүченең һәрбер электрон форма басуларын тутыру барышында Министрлык тарафыннан билгеләнгән таләпләр нигезендә автомат рәвештә Бердәм портал тарафыннан

башкарыла. Бердәм портал тарафыннан гаризаның электрон формасында дөрес тутырылмаган урыннар ачыкланганда гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны мәгълүмати хәбәр аша турыдан-туры электрон гариза формасында бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгате кергән көндә башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре:

электрон бәйләнеш системасы аша Министрлыкка җибәрелгән электрон эш.

3.7. Дәүләт хезмәтләрен күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар формалаштыру һәм җибәрү

3.7.1. Мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 2.6.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, Бүлек белгече катнашучы органнарга (оешмаларга) күрсәтелгән мәгълүмат алу өчен әлеге Регламентның 2.6.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлеге нигезендә ведомствоара запрос җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар әлеге Регламентның 3.6 пунктында каралган процедуралар тәмамланганнан соңгы өч эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: тиешле органнарга җибәрелгән запрослар.

3.7.2. Ведомствоара электрон бәйләнеш процессында катнашучы органнар әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны законнар белән билгеләнгән вакытта тапшыралар.

Процедуралар нәтиҗәсе: сорауларга җаваплар яки мәгълүмат җитмәү турында хәбәрләр.

3.8. Дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен әзерләү

3.8.1. Бүлек белгече тикшерү үткәрә:

документларны рәсмиләштерүнең дөреслеген (тапшырылган документларның закон белән билгеләнгән таләпләргә туры килүен формасы һәм эчтәлеге ягыннан, документларда кирәкле имзалар, мөһерләр, реквизитлар булуны, төзәтмәләр булмауны тикшерү);

бәяләнә торган хезмәтнең аның эчтәлегенә (күләме, вакыты, сыйфаты) билгеләнгән таләпләргә туры килүе;

иҗтимагый файдалы хезмәтләрне башкаруда турыдан-туры катнашкан затларның (шул исәптән оешма хезмәткәрләренең һәм гражданлык-хокукый характердагы шартнамәләр буенча җәлеп ителгән хезмәткәрләрнең) тиешле квалификациягә ия булулары (шул исәптән һөнәри белем, тиешле өлкәдә эшләү тәҗрибәсе), тиешле квалификациягә ия булган затлар санының җитәрлек булуы;

бәяләмә бирү турында гариза биргәнчегә кадәрге ике ел эчендә 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән килешүләрне үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча намуссыз тәэмин итүчеләр реестрында оешма турында бәяләмә булмау;

бәяләмә бирү турында гариза биргәнчегә кадәрге ике ел эчендә аларның компетенциясе буенча суд, дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек органнары, башка дәүләт органнары тарафыннан нигезләнгән, иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүгә бәйле оешмалар гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм (яки) карарларына шикаятьләр булмау;

мәгълүматның ачыклыгы һәм аны алу мөмкинлеге дәрәҗәсенең Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә (алар булганда) туры килүе;

әлеге Регламентның 2 нче кушымтасы нигезендә аңлатма хаты һәм бәяләмә проектларын әзерли, яки, әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән очракларда, әлеге Регламентка 2 нче кушымта нигезендәге форма буенча бәяләмә бирүдән баш тарту турында мотивлаштырылган белдерү проектын әзерли;

әзерләнгән документлар проектларын Бүлек башлыгына килештерүгә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар ведомствоара запросларга җавап алганнан соң биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: социаль ориентлашкан коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларына туры килүенә бәя бирү, Бүлек башлыгына килештерү өчен җибәрелгән документлар проектлары.

3.8.2. Бүлек башлыгы аңлатма хаты, бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында мотивлаштырылган белдерү проектларын тикшерә һәм аларны килештерү өчен министрның беренче урынбасарына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура әлеге проектлар килештерү өчен Бүлек башлыгына кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министрның беренче урынбасарына килештерүгә юнәлдерелгән аңлатма хаты, бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында мотивлаштырылган белдерү проектлары.

3.8.3. Министрның беренче урынбасары аңлатма хаты, бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында мотивлаштырылган белдерү проектларын килештерә һәм аларны министрга җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура әлеге проектлар килештерүгә кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килешенгән һәм министрга карауга юнәлтелгән аңлатма хаты, бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында мотивлаштырылган белдерү проектлары.

3.8.4. Министр бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында мотивлаштырылган белдерү белән булган аңлатма хатына кул куя, аларны Бүлек белгеченә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар әлеге Регламентның 3.8.3 пунктында каралган процедура тәмамланганнан соң биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: министр кул куйган аңлатма хаты, бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында мотивлаштырылган хәбәр.

3.9. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен бирү (тапшыру)

3.9.1. Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында хәбәр итә.

Техник мөмкинлекләр булганда процедураны үтәү дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып автоматлаштырылган режимда башкарыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура министр аңлатма хатына кул куйган көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: мәгълүмат системаларында дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыру, гариза бирүчегә (аның вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре һәм аны алу ысуллары турында хәбәр итү.

3.9.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен бирү (тапшыру) тәртибе

3.9.2.1. Мөрәҗәгать итүче Министрлыкка дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу өчен мөрәҗәгать иткәндә Бүлек белгече бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында мотивлаштырылган хатны гаризада күрсәтелгән ысул (шәхсән, почта, электрон почта, факс) белән тапшыруны (җибәрүне) гамәлгә ашыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура башкарыла:

гаризада бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында мотивлаштырылган хатны бирү ысулын почта аша (электрон почта, факс буенча) дип күрсәткәндә - бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында мотивлаштырылган белдерүне рәсмиләштерү көнендә;

гаризада бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында мотивлаштырылган белдерү бирү ысулын шәхсән дип күрсәткәндә – мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгате көнендә.

Процедуралар нәтиҗәсе: бирелгән (тапшырылган) бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында мотивлаштырылган белдерү.

3.9.2.2. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу өчен Бердәм портал аша (техник мөмкинлек булганда) яки Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына автомат рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган, Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган документның электрон образы җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне (дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту) раслаучы документ имзаланган көнне башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре түбәндәгеләр: мөрәҗәгать итүчегә Бердәм порталдан (техник мөмкинлек булганда) яки Республика порталыннан файдаланып дәүләт хезмәте күрсәтүне (шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуны) раслаучы документны җибәрү (тапшыру).

3.10. Техник хаталарны төзәтү

3.10.1. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Бүлеккә тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында ирекле формада төзелгән гариза (тәкъдим ителә торган форма әлеге Регламентка 3 нче кушымтада китерелгән);

гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хата булган документ;

техник хата булуын күрсәтүче юридик көчкә ия документлар.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдәге техник хаталарны төзәтү турында гариза гариза бирүче (вәкаләтле вәкил)

тарафыннан шәхсән яисә почта аша (шул исәптән электрон почта аша) яисә Бердәм портал аша (техник мөмкинлек булганда), яки Республика порталы аша бирелә.

3.10.2. Документларны кабул итү өчен җаваплы белгеч техник хатаны төзәтү турында гариза кабул итә, гаризаны беркетелгән документлар белән теркәп куя.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура Министрлыкка гариза һәм документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада килгән гариза ял  (бәйрәм) көненнән соңгы эш көнендә теркәлә.

Процедура нәтиҗәсе: документлар белән кабул ителгән һәм теркәлгән, карау өчен Бүлек белгеченә җибәрелгән гариза.

3.10.3. Бүлек белгече бәяләмәне йә бәяләмә бирүдән баш тарту турында мотивлаштырылган хәбәрне яңадан рәсмиләштерү максатыннан:

техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны һәм аңа кушып бирелгән документларны карый;

аңлатма хатын, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында мотивлаштырылган хәбәр проектларын әзерли;

әзерләнгән проектларны министрга имзалау өчен җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар әлеге Регламентның 3.10.2 пунктында каралган процедура тәмамланганнан соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: министрга җибәрелгән аңлатма хаты, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында мотивлаштырылган хәбәр.

3.10.4. Министр кабат рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында мотивлаштырылган белдерү белән булган аңлатма хатын имзалый һәм аларны  Бүлек белгеченә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар әлеге Регламентның 3.10.3 пунктында каралган процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабат рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында мотивлаштырылган белдерү белән булган, министр имзалаган аңлатма хаты

3.10.5. Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә бәяләмәне яңадан рәсмиләштерү яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында мотивацияләнгән хәбәрне техник хатаны төзәтү турында гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып хәбәр итә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар министр аңлатма хатына кул куйган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бәяләмәне яңадан рәсмиләштерү яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында мотивлаштырылган хәбәр.

3.10.6. Бүлек белгече яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында мотивлаштырылган хәбәрне тапшыруны техник хатаны төзәтү турында гаризада күрсәтелгән ысул белән (шәхсән, почта аша, электрон адрес, факс буенча)  гамәлгә ашыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура башкарыла:

техник хатаны төзәтү турындагы гаризада яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында мотивлаштырылган хәбәрне почта аша бирү ысулы күрсәтелгәндә (электрон адрес, факс буенча) – яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында мотивлаштырылган хәбәрне рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә;

техник хатаны төзәтү турындагы гаризада яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында мотивлаштырылган хәбәрне бирү ысулы күрсәтелгәндә - мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгате кергән көндә.

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелгән (җибәрелгән) яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында мотивлаштырылган хәбәр.

4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне контрольдә тоту формалары һәм тәртибе

4.1. Җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан Регламент һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләрне билгели торган башка норматив хокукый актлар нигезләмәләрен үтәүгә, шулай ук аларның карарлар кабул итүләренә агымдагы контрольне гамәлгә ашыру тәртибе

4.1.1. Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләренең һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгеләүче башка норматив хокукый актларның үтәлешен һәм башкарылуын, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүне агымдагы контрольдә тоту тиешле административ процедураны үтәү өчен җаваплы зат, Бүлек башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.1.2. Агымдагы тикшерү Министрлыкның урындагы затлары тарафыннан Регламент нигезләмәләренең һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актларның сакланышын һәм үтәлешен тикшерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы тикшерү даими нигездә башкарыла.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын планлы һәм планнан тыш тикшерүләрне гамәлгә ашыруның тәртибе һәм вакыт аралыгы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп тору тәртибе һәм формасы

4.2.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатлылыгын тикшерүдә тоту үз эченә тикшерүләр үткәрүне, карарларны карау һәм кабул итүне һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы урындагы затларның карарларына, гамәлләренә (гамәлләр кылмауларына) шикаять белдергән мөрәҗәгатьләргә җаваплар әзерләүне ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып тикшерүләр үткәрү тора:

эш башкаруны, шул исәптән документларны кабул итү срокларын һәм тәртибен үтәүне;

документларны карау нәтиҗәләренең законнар (әлеге Регламент) таләпләренә туры килүе;

дәүләт хезмәте күрсәтү срокларын, тәртибен үтәү.

Тикшерүләр үткәрүнең ешлыгы планлы (эш планнары нигезендә башкарыла) һәм планнан тыш (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) характерга ия.

4.2.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатлылыгын планнан тыш тикшерү турындагы карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1)Регламентның һәм башка норматив хокукый актларның дәүләт хезмәтен күрсәтүгә булган таләпләренең бозылуына алда табылган җитешсезлекләрне бетерүне тикшерү белән бәйле рәвештә;

2) юридик затларның Министрлыкның дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы урындагы затларының гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуларына шикаятьләр белән мөрәҗәгать итүләренә бәйле рәвештә.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затларының дәүләт хезмәте күрсәтү барышында кабул ителә торган (гамәлгә ашырыла торган) карарлары һәм гамәлләре өчен җаваплылыгы

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очрагы ачыкланса, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган һәм гаепле дип табылган затлар, Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартылалар.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибенә һәм формаларына, шул исәптән гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан таләпләрне характерлаучы нигезләмәләр

Дәүләт хезмәтләре күрсәтелүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан тикшерүдә тоту Министрлыкның дәүләт хезмәтләре күрсәтүдәге эшчәнлегенең ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүматлар алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге юлы белән гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органның, дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 11 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләренең карарларына, кылган гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүчеләр Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карарларына, кылган гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата судка кадәр Министрлыкка шикаять белдерүгә хокуклылар.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле рәвештә министр кабул иткән карарларга карата белдерелгән шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

5.2. Мөрәҗәгать итүче шикаять белән шул исәптән түбәндәге очракларда да мөрәҗәгать итә ала:

1) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 151 статьясында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтүне, запросны теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар, мәгълүматлар яки гамәлләр кылу таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаса;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

7) Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканда яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гариза бирүчедән документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда аларның булмавы һәм (яки) дөрес түгеллекләре күрсәтелмәгән, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган, яки дәүләт хезмәтен күрсәткән чакта кирәкле булган документлар яки мәгълүмат таләп итү, «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешнең 4 пунктында каралган очраклардан тыш.

5.3. Шикаять кәгазь күчергечтә язма рәвештә яки электрон формада бирелә.

Шикаять почта аша, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша, Министрлыкның рәсми сайтыннан, Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып җибәрелә ала, шулай ук гариза бирүчедән шәхсән кабул ителергә мөмкин.

Шикаять ул кергән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмый теркәлергә тиеш.

5.4. Шикаять теркәлгән көннән алып 15 эш көне эчендә каралырга тиеш. Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты яисә дәүләт граждан хезмәткәре гариза бирүчедән документларны кабул итмәүгә яки хаталарны төзәтүдән баш тартуга шикаять белдерелгәндә яки хаталарны төзәтүдә билгеләнгән срок бозылган очракта шикаять теркәлгән көннән биш эш көне эчендә карала.

5.5. Шикаять үз эченә түбәндәге мәгълүматларны алырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яки дәүләт граждан хезмәткәренең исемен;

2) гариза бирүченең яшәү урыны турында мәгълүматлар, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), гариза язучыга җавап җибәрелергә тиешле электрон почта (булса) адресы (адреслары) һәм почта адресы;

3) Министрлыкның, аның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм кылган гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең Министрлыкның, аның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең карары һәм кылган гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешмәвенә дәлилләре.

5.6. Гариза бирүче тарафыннан гариза бирүченең дәлилләрен раслаучы документлар (яки аларның күчермәләре) тапшырыла ала (алар булган очракта).

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләре турында бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны төзәтү, гариза язучыга аларны алу Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында каралмаган акчаларны кире кайтару формаларында;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Гариза язучыга әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча язма формада һәм гариза язучының теләге буенча, электрон формада да, шикаять каралу нәтиҗәләре турында мотивлаштырылган җавап җибәрелә.

Шикаять канәгатьләндерелүгә лаек дип танылган очракта гариза бирүчегә җавапта Министрлык тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән чакта табылган җитешсезлекләрне кичекмәстән төзәтү максатыннан гамәлгә ашырылачак гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук килеп туган уңайсызлыклар өчен гафу сорала һәм гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтен алу максатыннан башкарылырга тиешле гамәлләр турында мәгълүмат бирелә.

Шикаять канәгатьләндерелүгә лаек түгел дип танылган очракта гариза бирүчегә җавапта мондый карар кабул ителү сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирдерү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.8. Шикаятьне карау барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки җинаять составы ачыкланган очракта шикаятьләрне карау буенча урындагы зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына юллый.

Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүләре турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

тәкъдим ителә торган форма

Татарстан Республикасы юстиция министрына
___________________________________
(фамилия, инициаллар)
______________________________
______________________________ (оешма исеме, адрес (почтаһәм (яки) электрон), телефон номеры (булганда)

ГАРИЗА

Сездән социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешма
______________________________________________________________
(социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешма исеме)
тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтнең
______________________________________________________________
(иҗтимагый файдалы хезмәт аталышы)
билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмә бирүегезне үтенәм.

Оешманың чит дәүләт агенты функцияләрен башкаручы коммерцияле булмаган оешма түгеллеген, һәм бер ел һәм аннан артыграк вакыт дәвамында иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатының Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Иҗтимагый файдалы хезмәтләр исемлеген һәм аларны күрсәтү сыйфатын бәяләү критерийларын раслау турында» 2016 елның 27 октябрендәге 1096 номерлы карары белән расланган критерийларына туры килә торган санап кителгән иҗтимагый файдалы хезмәтләрне күрсәтүен раслыйбыз:
______________________________________________________________
______________________________________________________________

(иҗтимагый файдалы хезмәтнең Россия Федерациясенең норматив хокукый актларына туры килүе һәм аның эчтәлегенә таләпләр (күләме, сроклары, күрсәтү сыйфаты)

______________________________________________________________

______________________________________________

(иҗтимагый файдалы хезмәт кнрсәтүдә турыдан-туры җәлеп ителгән затларның (шул исәптән оешма хезмәткәрләренең һәм гражданлык-хокукый характердагы килешүләр нигезендә җәлеп ителгән хезмәткәрләрнең) тиешле квалификациягә (шул исәптән профессиональ белемгә, бу өлкәдә эш тәҗрибәсенә) ия булулары, мондый затларның тиешле күләмдә булулары)

______________________________________________

______________________________________________

(бәяләмә бирү елы алдыннан булган ике ел эчендә иҗтимагый файдалы хезмәтләр алучыларның аларны күрсәтү сыйфатыннанканәгать булулары (оешманың иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү белән бәйле гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм карарларына суд, дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек органнары, аларның компетенцияләре чикләрендә башка органнар тарафыннан нигезләнгән шикаятьләр булмау)

______________________________________________

______________________________________________

(коммерцияле булмаган оешма турындагы мәгълүматның ачыклыгы)

______________________________________________

______________________________________________

(бәяләмә бирү елы алдыннан булган ике ел эчендә оешманың «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән килешүләрне үтәү кысаларында хезмәт күрсәтүләр нәтиҗәләре буенча гадел булмаган тәэмин итүчеләр реестрында тормавын раслау)

Раслаучы документлар өстәп бирелә:

1. ______________________________
2. ______________________________
3. ______________________________

______________________________________________

вазыйфа имза фамилия, исем, этисенең исеме (булганда)

«___»____________20__ел.

М.У. (булганда)

Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүләре турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

тәкъдим ителә торган форма

Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүләре турында бәяләмәләр бирүдән баш тарту турында нигезле белешмә

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү нәтиҗәләре буенча социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешма тарафыннан

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

(социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешманың тулы исеме һәм төп дәүләт теркәлү номеры)

күрсәтелә торган түбәндәге иҗтимагый файдалы хезмәтләр

______________________________________________________________________________;

______________________________________________________________________________;

______________________________________________________________________________.

(иҗтимагый файдалы хезмәт аталышы)

сыйфатларының билгеләнгән критерийларга туры килүләре турында бәяләмә бирүдән баш тарта.

Күрсәтелгән иҗтимагый файдалы хезмәтләр иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатының билгеләнгән критерийларына түбәндәге нигезләр буенча туры килмиләр:

_________________________________________________________________________.

(критерийларга туры килмәве күрсәтелә)

Татарстан Республикасы
Юстиция министры ______________/________________________

имза фамилия, исем, әтисенең исеме (булганда)

«___»___________20__ел.

М.У. (булганда)

Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүләре турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

тәкъдим ителә
торган форма

___________________________________________

(дәүләт хезмәтен күрсәтүче

_______________________________________

органның исеме)

_______________________________

_______________________________

(оешманың исеме, почта һәм (яки) электрон
адрес, телефон номеры (булганда)

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмә биргәндә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле аңлатма хатында җибәрелгән хата турында хәбәр итәм.

Документта ______________________________________________________________

________________________________________________________________________

(бирелгән документның исеме) диелгән.

Дөрес мәгълүматлар:

_________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булып торучы документка тиешле үзгәрешләрне кертүегезне үтенәм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

3.

Документның әзерлеге турында түбәндәге алым белән белдерүегезне үтенәм

__________________________________________________________________________

(белдерү алымы)

| | | |
|---|---|---|
| ____________ | _________________________ | ________________________________ |
| (дата) | (гариза бирүче/вәкил имзасы) | (Ф.И.Ә.и.) |

Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүләре турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмәлек)

# СОЦИАЛЬ ОРИЕНТЛАШКАН КОММЕРЦИЯЛЕ БУЛМАГАН ОЕШМАЛАР ТАРАФЫННАН КҮРСӘТЕЛӘ ТОРГАН ИҖТИМАГЫЙ ФАЙДАЛЫ ХЕЗМӘТЛӘРНЕҢ БИЛГЕЛӘНГӘН КРИТЕРИЙЛАРГА ТУРЫ КИЛҮЛӘРЕ ТУРЫНДА БӘЯЛӘМӘЛӘР БИРҮ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕ КҮРСӘТҮ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ УРЫНДАГЫ ЗАТЛАРНЫҢ РЕКВИЗИТЛАРЫ

## Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | (843) 222-60-00 | minjust@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасары | (843) 222-60-02 | Aynur.Galimov@tatar.ru |
| Түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне оештыру һәм планлаштыру бүлеге башлыгы | (843) 222-60-49 | Ilfat.Mingalimov@tatar.ru |
| Оештыру эшләре һәм документлар әйләнеше бүлеге | (843) 222-60-07 | Farida.Nurieva@tatar.ru |

## Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Адрес | Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|---|
| 420014, Казан шәһ., Ирек мәйданы, 1 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының хокукый идарә башлыгы | (843) 264-76-25 | Marat.Dolgov@tatar.ru |